Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
## УНИВЕРСИТЕТ

12+

№15 (145)

4 декабрь 2015 ел




Фото С.Мостафина архивыннан

*Кыш белән көз бил алышканда, Татарстанның иң чибәр, уңган, акыллы һәм сәләтле студент кызлары матурлык бәйгесендә көч сынашты. «Студентлар гүзәле-2015»тә катнашырга теләк белдергән 150 туташның 22се финалга үтте. Кызлар дефиле белән генә чикләнмичә, үз сәләтләрен иҗади номерлар ярдәмендә дә күрсәттеләр. Җиңүчеләр арасында КФУ студентларының булуы тагын да сөендерә. «Татарстан Республикасы студентларының беренче гүзәле» исеменә Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты студенты Софья Мостафина лаек булды.*

**• Вакыйгалар эзеннән**

### ЯНА КӘРӘЗЛЕ ТЕЛЕФОН

КФУда узган Ачык лекция кысаларында, ИТИС Югары мәктәбендә Qualcomm компаниясе вице-президенты Джордж Виттен чыгыш ясады. Очрашу барышында ул патентлы гаризалар бирү һәм шул өлкәдә акча эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашты. Моннан тыш, Джордж Виттен тормышыбызның аерылгысыз бер өлешенә әйләнгән кәрәзле телефоннар турында сөйләде. «Бүгенге көн технологияләре ярдәмендә студентлар кәрәзле телефоннарның өр-яңа модельләрен булдыра ала», – дип белдерде ул. Ә ИТИС Югары мәктәбе студентларының бу өлкәдә уңышларга ирешү мөмкинлеге бигрәк тә зур.





### ДӘРӘҖӘ АРТА

КФУның Бионанотехнология фәнни-тикшеренү лабораториясе җитәкчесе, биология фәннәре докторы Равил Фәхруллин дөньякүләм танылган RSC Advances фәнни журнал коллегиясе составына кертелгән. Әлеге басма Scopus һәм Web of Science мәгълүматлар базасында урын алган, химиянең барлык өлкәләрен, шул исәптән, биологик аспектлар белән бәйләнешен тирәнтен өйрәнә. Равил Фәхруллинның коллегия составына алынуы КФУның фәнни эшчәнлеге югары бәяләнүен күрсәтә. «Чит ил журналларында күбрәк басылган саен, университетыбызның дәрәҗәсе артачак», – дип ассызыклады Равил Фәхруллин.

### «MANUSCRIPTS DON'T BURN»

КФУда Чит телләр атналыгы уза. 1 нче декабрьдә «Кульъязмалар янмый» темасына багышланган СТЭМнар конкурсында I урынны – А.М. Бутлеров ис. Химия институты, II урынны – ИТИС югары мәктәбе һәм III урынны Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студентлары яулады. 2 нче декабрьдә булган Чит телдәге җырлар фестивалендә Александра Власова (А.М. Бутлеров ис. Химия институты), Дарья Масальская (Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты), Александр Никаньшинның (А.М. Бутлеров ис. Химия институты) чыгышлары иң яхшы дип табылды. Атналык традициягә әверелгән «Полиглот» конкурсы белән тәмамланачак.



• Ректорат

Казан (Идел буе) федераль университетының чираттагы ректораты яңа фәнни үзәкләр ачу, яңа эшләнә торган уку-укыту проектларының киләчәге турында фикер алышты.

# КФУда яңа үзәк ачыла

Чыгышларның берсе Математик белем бирү буенча өстенлек үзәген оештыруга багышланган иде. Аның ачылышы киләсе елга планлаштырыла. Әлеге проектның үзенчәлекләре турында үзәк җитәкчесе **Андрей Фролов** түбәндәгеләрне җиткерде: алар Россиядә 4 кенә булачак (Казанда, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм Новосибирскида). Үзәкләр РФдә математик белем бирүне үстерү концепциясен гамәлгә кую кысаларында оештырыла. Бу, үз чиратында, педагогларның квалификациясен арттыруга, математик белем бирүнең структурасын һәм эчтәлеген яңартуга көчле этәргеч булачак.

Ректор **Илшат Гафуров** Өстенлек үзәгенең Юл картасын төзергә һәм дөньядагы мондый үзәкләрнең эшләү рәвешен анализларга кирәклегенә басым ясады.

Физика институты директоры **Сергей Никитин** үзенең чыгышында В.П.Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясенең планетарий мәйданнары уку аудиторияләре һәм практика узу өчен база булачак файдаланылуын әйтте. Обсерваториядә, уку-укыту һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеген алып барудан тыш, укучылар өчен астрономия буенча кышкы һәм җәйге мәктәпләр оештырыла. Әлеге мәсьәләгә карата Илшат Гафуровның өстәмә фикере дә бик урынлы яңгырады: «Обсерватория – ял базасы булачак та бик яхшы урын. Мисал өчен, КФУ хезмәткәрләре, студентлары биредә чаңгыда шуа алырлар иде».

• Бездә кунак бар

# Гаилә нигезе турында

**Руфинә ДУНАЕВА**

Һәр елда ноябрьнең соңгы якшәмбесе Әниләр көне буларак билгеләп үтелә. Әлеге көн уңаеннан КФУда Россия Федерациясе Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасы Елена Мизулина ачык лекция укыды.



Статистика буенча 10 яңа туган гаиләгә 8 аерылышу туры килә икән. «Сәламәт гаилә тормышы» дигән төшенчә юкка гына кулланылмый, чөнки җәмгыятьнең киләчәген нигезе нык, тәрбияле, белемле гаилә кора.

Беркемгә дә сер түгел, бу ханым гаилә кыйммәтләрен канун дәрәҗәсенә күтәрүгә күп көчен куя.

**Елена Борисовнаның** Казанга килүенең сәбәбе – «Ана булу изгелеге» дип аталган Бөтенроссия программасының Дүртенче форумы. Бер сәгатьлек чыгышында Мизулина бик күп мәсьәләләргә игътибар юнәлтергә өлгерде: үзенең галим һәм дәүләт эшлеклесе булып җитлегү тарихы, Россия Гаилә кодексының үсеш-үзгәреше турында сөйләде. Кодексның көчсез якларына ишарәләп, камилләшү юнәлешләрен дә искәртте. Әлбәттә, суррогатлык, аборт проблемалары да читтә калмады.

Елена Мизулина башта гаиләгә караган кануннар – хокукның иң конфликтсыз һәм җиңел өлкәләренең берсе, дип фикер йөрткән. Соңрак исә ялгышканын аңлаган. «2008 елда мине Дәүләт думасының Гаилә, хатын-кыз һәм балалар комитеты җитәкчесе итеп билгеләделәр. Шул вакытта гына гаилә һәм гаилә сәясәте мәсьәләләре идеологик юнәлешне тәшкил итүен аңладым», – дип искәртте Мизулина.

1995 елда кабул ителгән Россия Гаилә кодексы, өлешчә булса да, СССРның Өйләнү һәм гаилә турындагы кодексына нигезләнә. Яңа бүлекләре, совет дәүләте җимерелгәннән соң, чит ил законнарына мөрәҗәгать иткән. 2008 елга кадәр гаилә турындагы законнар, башка кодекслар берничә мәртәбә кабаттан язылган булса да, бөтенләй диярлек үзгәреш кичермәгән. Мизулина фикеренчә, Гаилә кодексының совет заманы законнарына нигезләнүе хәзерге яшәешкә гомумән туры килми. Искә генә төшерик: ул чорда көчле совет идеологиясе хөкем сөргән, мондый җәмгыятьтә гаиләнең кыйммәте югары саналмаган. Чит ил кануннарыннан алынган өлешләрдә исә суррогатлык һәм бер җенестәге кешеләрнең гаилә кора алу хокуклары язылган. «20 ел элек кабул ителгән документта мондый мәсьәләләрнең күтәрелүе гаҗәп. Хәтта медицина кануннарында да моның турында бер сүз дә булмаган. Нишләп берәү дә моңа игътибар итмәгән икән?» – дип, аптыравын белдерде Елена Борисовна.

Лекциядә, КФУ студентларыннан тыш, Мәскәү, Сарытау, Самара, Чиләбедән килгән кунаклар да үзләрен кызыксындырган мәсьәләләрне кузгатты. Татарстан парламентарийларының аерылышу процессын катлауландыру инициативасы турында да сүз булды. Елена ханым әлеге закон проектын хуплавын белдерде. «Аерылышу – ни генә булса да, иң соңгы чара. Бүген аерылышу процессы бик җиңел. Ә бит һәрвакыт мәхәббәткә илтә торган юлны эзләргә кирәк, ашыкмаска. Беребезне дә өйләнергә яки кияүгә чыгарга мәҗбүр итмиләр. Мондый җитди адымны һәркем үзе ясый».

• Туган тел сагында

# Телләр өйрәнүнең әһәмияте

**Гөлназ МӨГЪТӘСИМОВА,** гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы доценты

Лев Толстой исемендәге Филология һәм халыкара багланышлар институтында ике һәм күптеллелек шартларында дәүләт һәм төбәк телләре кулланылышының хокукый нигезләре турында сөйләштеләр.

«Ике һәм күптеллелек шартларында дәүләт һәм төбәк телләре кулланылышының хокукый нигезләре (федератив дәүләт шартларында тел сәясәтен гамәлгә куюда дөнья тәҗрибәсе)» дип исемләнгән Халыкара фәнни-гамәли конференция Филология һәм халыкара багланышлар институтының гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы тарафыннан уздырылды.

Конференциядә катнашучылар арасында АКШ, Төркия, Германия, Казахстан, Кыргызстан галимнәре, Мәскәү дәүләт институты профессоры Е.Ф.Киров, Татарстан Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлекчәсе мөдире, язучы Галимҗан Гыйльманов һәм ТР Конституция суды вәкилләре дә бар иде.

Конференция вакытында куелган барлык проблема-бурычлар: күпмилләтле төбәгебездә милли тәңгәллекне, туган телләрне саклау һәм үстерү, дәүләт һәм төбәк телләре кулланылышының хокукый нигезләре мәсьәләләре бүгенге көн өчен бик актуаль.

Чарада катнашучылар, милли тәңгәллекне, рухи һәм мәдәни мирасны саклау, үстерү чарасы буларак, туган телләрне саклауга һәм өйрәнүгә кызыксынуны арттыру турында фикер алышты. Россия Федерациясенең милли республикаларында икенче дәүләт теленең мөмкинлекләрен ассызыклап, Ә.Г.Нуриев конференциядә катнашучыларны уйланырга мәҗбүр итте. Чыгыш ясаучылар туган телне яңа белем бирү стандартларына нигезләнеп укыту һәм милли тәрбия мәсьәләләренә дә тукталдылар. Фикер алышуларга йомгак ясап, Татарстан Республикасында тел сәясәтен норматив хокукый тәэмин итүне камилләштерү, җәмгыятьтә милли тәңгәллекне, телләр өйрәнүнең әһәмиятен үстерү, киләчәк буыннарда үз халкына, мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү зарурлыгы ассызыкланды. Катнашучылар, килгән кунаклар һәм галимнәр фәнни-гамәли конференциянең оештырылу дәрәҗәсеннән бик канәгать калдылар, уңышлар теләделәр.



■ КФУның Алабуга институты профессоры Дания Сәлимова. Булат Айзатуллов фотосы.

• Чара

2 нче декабрь көнне Татарстан Республикасы Милли музее бинасында татар матбугатының 110 еллык юбилеена багышланган тантаналы чара узды.

# Татар матбугатына 110 ел!

**Инсаф МИҢНЕХУҖИН,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты



Татар матбугаты кызыклы һәм мавыктыргыч тарихка ия. Беренче булып, 1905 нче елның 2 нче сентябрендә Санкт-Петербург шәһәрендә «Нур» газетасы дөнья күрә. Ул Гатаулла Баязитов инициативасы белән чыга һәм 1914 нче елга кадәр басыла. Шулай ук, кичә барышында уникаль экспонатлар тәкъдим ителде: Лобачевский исемендәге китапханә җыентыгыннан «Нур» һәм «Казан мөхбире» газеталары, ТР Милли музее фондыннан төрле газета-журналлар белән танышу бәхетенә ирештек.

Килгән кунакларны татар матбугатының тарихы белән ачыграк итеп татар журналистикасы кафедрасы мөдире, профессор **В.З.Гарифуллин**, Лобачевский исемендәге интернат-мәктәбе укытучысы **Ф.М.Мөхәммәтшин** һәм ТР Милли музее хезмәткәре **Р.А.Абзалина** таныштырып китте. Әинде әдәби-музыкаль программаны театр эстрадасы кафедрасы студентлары тәкъдим иттеләр.

• Шәхес

Казанда танылган журналист Владимир Познерның иҗат кичәсе үтте. Чара бүгенге көннең актуаль проблемаларына кагылышлы монолог белән башланып китте. Алар арасында террорчылык, түземлелек, миграция, бүгенге журналистика һәм патриотизм темалары яңгырады.

# Владимир Познер: «Журналистика – күңел халәте»

**Әлмира ӘГЪЗАМОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Һәрбер җиткергән фикерен В.Познер шәхси тормышыннан мисаллар белән бәйләп барды. Аның сәяхәтләре, Франция һәм АКШта яшәү, медиа өлкәсендәге кешеләр белән аралашу тәҗрибәсе бай һәм киң. Владимир Владимирович фикеренчә, бүген объектив мәгълүмат алу кыенлаша. Бу вакыйгаларның төрле илләрдә төрлечә күрсәтелүенә бәйле, ди. «*Мин үзем, Россия яңалыкларын караган кебек үк, чит илнекен дә карап барам. Моның өчен күп вакыт һәм зур теләк кирәк*», – ди журналист.




Кичәнең икенче бүлеге тамашачылар белән әңгәмә рәвешендә үтте. Сораулар даирәсе киң иде: рэп темасыннан алып, сүз ирегенә кагылган мәсьәләләргә кадәр. Микрофон тотып сорау бирүчеләр арасында КФУ студентлары да байтак иде. «*Безнең илдә дәүләттән башка яшәүче, ирекле каналлар юктыр ул*», – дип белдерде Познер. Россиянең киләчәге турында да юмор белән җавап бирде: «*Бәллүр шарым бар иде. Ул һәрвакыт ни буласын күрсәтеп бирә иде. Менә, күп сәяхәтләремнең берсендә мин аны югалтканмын. Шуннан бирле илебезнең киләчәге турында берни дә әйтә алмыйм*», – дип көлдерде Владимир Познер.

Мәгариф өлкәсенә килгәндә, журналистика мэтры БДИга тискәре караштa икән. Тамга сугып, дөрес җавап эзләп утыру – балаларның фикерләү сәләтен киметә, диде ул. Шулай ук журналистика факультетында укуның да кирәген тапмады: «*Журналистлыкка укып булмый, журналистика – күңел халәте, яшәү рәвеше*», – диде.

Кичә барышында Татарстан сәясәтчеләренә кагылышлы сорау да яңгырады. Аерып әйткәндә, тамашачылар аның беренче президент Минтимер Шәрипович Шәймиевкә карата мөнәсәбәтен сорадылар. «*Шәймиев – искиткеч кеше. Мин аны хөрмәт итәм. Бер сәясәтче дә урыныннан үзе китми, ә ул китте. Бу аның зирәклеге турында сөйли*», – диде ул.

Профессиясенә, сәясәткә, илнең киләчәгенә кагылышлы сораулардан тыш, шәхси тормышына, эчке дөньясына бәйле сорау бирүчеләр дә табылды. Сезнең өчен бәхет нидә, дигән сорауга Познер: «*Үз-үзеңне яраткан эшеңдә, балаларыңда һәм якын кешеңдә табу*», – дип җавап бирде.

Кичә ахырында танылган журналист оештыручылардан бүләк буларак үз сурәтен кабул итте. Чарадан соң, теләүчеләр Познер белән фотога төшеп, аның автографын алу мөмкинлегенә ия булдылар.

Фикерләргә өйрәтүче сәләтле ораторлар безнең калада ешрак булсыннар иде. Әлеге иҗат кичәсеннән киләчәккә якты планнар корып, дәртләнеп, көч алып кайтып китүче журналистлар күп булгандыр.

• Премьера

# «Мизгел»нең гамьле мизгеле

3 нче декабрь көнне «Мизгел» Яшьләр театры тамашачы игътибарына үзенең әр-яңа спектаклен тәкъдим итте. «Соң иде шул» дип исемләнгән әлеге әсәр Мостай Кәримнең «Ике хат» хикәясе буенча куелган.

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**



Соңгы елларда әдәбиятка, бигрәк тә драматургиягә зур игътибар бирелә. Республикада Әдәбият елы кысаларында бер-бер артлы берничә бәйге уздырылды. Яшь каләм осталарының әсәрләре Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры, «Угол» иҗат лабораторияләрендә сәхнәләштерелде. Мондый спектакльләр күплегендә югалып калмау һәм, бигрәк тә аерылып тору, шактый читен. Тик «Мизгел» Яшьләр театрына берни куркыныч түгел.

«Соң иде шул» әсәре «Мизгел»нең моңа кадәр куйган тамашаларыннан аерыла. Сәхнәдә дистәгә якын герой һәм берничә сюжет сызыгы күреп өйрәнгән тамашачы өчен, бу спектакль минимальлеге белән дә истә калды. Режиссер – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты **Марсель Җаббар** – язучының үзе белән таныш була.

Вакыйгалар барысы да Ялтада бара. Сугыштан соңгы авыр еллар ачлык, ялангачлык белән генә түгел, туберкулез, чахотка кебек авырулар белән дә җәфалый кешеләрне. Кырымга килеп эләккән төп каһарманнар да шуның белән иза чигәләр.

Спектакль тулысынча истәлекләр рәвешендә ясалган. Төп каһарманнарның берсе – Капитан – сөйгәне Таңсылуның үлеме турында кайгылы хәбәр ала. Әсәрнең башында ук ике гашыйк арасындагы мәхәббәтнең гөнаһлы һәм фаҗигале булуы ачыклана. Чөнки берсе ир хатыны булса, икенчесе – бала атасы. Икесен дә өйләрендә гаиләләре һәм көндәлек тормыш мәшәкатьләре көтә. Ләкин эчкерсез хатлар, саф, самими мөнәсәбәтләрдә генә яшәгән әлеге сөюгә берни дә киртә була алмый. Капитан ролен башкаручы **Нияз Вәлиуллин** ир кешенең ни кадәр йомшак күңелле һәм хыялый була алуын күрсәтте. Моның өчен берниндии артык хәрәкәт, артык сүз дә кирәкми икән. Капитанның бер ягымлы карашы йөрәк түрендә, җиде кат йозак астында саклаган серләрне сөйли алды.

Ә Таңсылу ролен башкарган **Эльвина Нәҗипова** ихластан яраткан хатын-кызның нинди булуын бик оста сурәтләде. Акыл белән никадәр генә эш йөртергә тырышса да, Таңсылу хисләр ташкынына күмелә. Бер мизгелгә генә иңнәренә кунган бәхетне югалтмыйча саклап калырга омтыла. Әлбәттә, тамашачыларда фикер төрлелеге барлыкка килде. Берәүләр Таңсылуның халәтен аңласа, икенчеләр автор тәкъдим иткән образны гаилә учагын сүндерүдә, чын ир хатыны һәм чын ана була белмәүдә гаепләргә ашыкты. Үлем түшәгендә саташып ятканда да, Капитанны искә алуы һәм аны чакыруы тамашачыны каршылыклы уйлар дәрьясында калдырды.

Спектакльне сәхнәләштерүгә үз өлешен керткән һәркем тамашачыларга рухи байлык һәм онытылмаслык хисләр бүләк итте.

• Яшьлек – яңарыш

# Студентлар колагына

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

Студентлар «Шимбә, якшәмбе көнне нишләргә икән?» дип, баш ватып утырмый. Актив яшьләр үзләренә һөрчак берәр шөгыль яки кызыклы вакыйга таба. Бөтендөнья татар яшьләре форумы татар яшьләре өчен мондый чараларны еш оештыра. Мәсәлән, Татарча рэп-баттл.

Баттл – безнең хип-хопта Slovo һәм Versus проектлары белән кертелгән яңа тренд. Кара-каршы чыгып, башкаручылар «дошманнарын» панчлар һәм рифмалар ярдәмендә җиңәләр, ә шушы хәлне төшереп алган видеоязмалар еш кына миллионлаган карау җыя. Татар рэпы җилнең кайдан исәнен белә һәм үз версиясен тәкъдим итә. 21нче ноябрь көнне Совет уен автоматлар музеенда шундый татарча баттлларның берсе – иң мөһиме, иң беренчесе узды! Баттлда сигез яшь башкаручы катнашты – барысы да, «ВКонтакте» төркеме аркылы гариза биреп, экспертлар ярдәмендә сайланды. Алар өч раундта көч сынашты: дисреспект, респект һәм ирекле тема. Ә җиңүчене тамашачы билгеләде. Чарада **Ittifaq**, **K-Ru**, **G.Raf** кебек татар музыка дөньясында танылып өлгергән башкаручылар да чыгыш ясады.

Ә беренче татарча рэп-баттлының җиңүчесе – **Funt**! Аңа Yummy Musicтан җыр яздыру, Artсурәттән видео-клип төшерү мөмкинлеге һәм «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә катнашу өчен сертификат тапшырылды.

Эх, күрми калдым, белми калдым, дип борчылырга ашыкмагыз! Якын арада тагын бер зур вакыйга көтелә: 3 нче декабрь көнне «Акыл фабрикасы» проекты старт алды. Башка регионнар, чит илләрдән килгән сәләтле, актив татар яшьләре, оешма җитәкчеләре өчен интенсив мәктәп бу.

Аның кысаларында белем бирү һәм проектлар төзүгә багышланган төрле форматтагы чаралар планлаштырыла, мәсәлән, галимнәр һәм экспертлар белән очрашу, ачык дискуссияләр, практика һәм воркшоплар, стратегик сессияләр.

Проектның төп үзенчәлеге – аның ике телдә үтүе. Ахырда барлык укучыларга лицензияле сертификат тапшырылачак.

Республикабыз һәм илебезнең алдынгы талантлы яшьләре белән аралашу, уникаль белем туплау һәм экспертлардан файдалы киңәшләр ишетү мөмкинлеген кулыңнан ычкындырма!

• Белдерү

**КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ОБЪЯВЛЯЕТ**

***конкурс на замещение должностей профессорско-преподавательского состава:***

● **Институт геологии и нефтегазовых технологий:**
***старший преподаватель:***
- кафедры региональной геологии и полезных ископаемых – 1 (1) ;

● **Институт филологии и межкультурной коммуникации:**
***старший преподаватель:***
- кафедры романской филологии – 1 (1);
- кафедры контрастивной лингвистики – 1 (1);

● **Институт экологии и природопользования:**
***старший преподаватель:***
- кафедры ландшафтной экологии – 0,8 (1);

● **Юридический факультет:**
***доцент:***
- кафедры уголовного права – 1 (1);

● **Институт математики и механики им. Н.И.Лобачевского:**
***профессор:***
- кафедры общей математики – 1 (1);

● **Институт вычислительной математики и информационных технологий:**
***старший преподаватель:***
- кафедры математической статистики - 1 (1);

ЗАЯВЛЕНИЯ вместе с документами, подтверждающими квалификацию кандидата, принимаются в Управлении кадров КФУ (420008, г. Казань, ул.Кремлевская, 18 каб.132 главного здания).

Информация о конкурсе, о сроках и месте проведения конкурса размещается на сайте Управления кадров официального портала КФУ ***kpfu.ru.***

**Аклы-каралы дөнья**

*3 нче декабрь – Халыкара инвалидлар көне*

# Түземлеләр генә бәхеткә лаек

**Руфинә ДУНАЕВА**

Аңлатмалы сүзлектә инвалид сүзе болай бирелә: «Инвалид – авыру яки имгәнү сәбәпле хезмәткә яраклылыкны өлешчә яки тулысынча югалткан кеше». Физик мөмкинлекләрдән тыш, тагын бер тасвирламага игътибар итәргә кирәктер: инвалид ул – язмышын кабул иткән шәхес.

Инвалидларның проблемаларын хәл итүдә ярдәм күрсәтү – башкарылырга тиешле гамәл, бурыч. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кеше булсалар да, аларның күпчелеге, һәр ике куллы, ике аяклы, сәламәт кешегә караганда, күпкә тирәнрәк, исәнрәк, бәхетлерәк.

**Ник Вуйчич** – танылган оратор. Кулсыз, аяксыз булып туына карамастан, уңышлы карьера төзегән, өйләнгән, әти булу бәхетенә ирешкән. Үз үрнәге белән ул башка кешеләрне авырлыкларны җиңәргә һәм начарлыкны яхшылыкка әверелдерергә илһамландыра. «Чикләүләрсез тормыш» («Жизнь без границ») китабында ул болай дип яза: «Мин – чын инвалид, ләкин шул ук вакытта тулы тормыш белән яшим. Уникаль халәтем минем алдымда күп мөмкинлекләр ачты – тормышта авырлыкка юлыккан кешеләр белән аралашу. Без үз мөмкинлекләребезне үзебез чиклибез».

Үз танышларым арасында да мондый шә-



хесләр бар. 24 яшьлек гап-гади Казан егете, студент Ислам белән без очраклы рәвештә таныштык. Социаль челтәрдә «Ачыктан-ачык үсеш» төркеменә юлыктым. Бу сәхифәдә **Ислам Гаязетдинов** исемле егет үзенең максатлары, аларга ничек ирешүе турында язмалар урнаштыра икән. Үзенә күрә блог алып бара. Аның язмаларын укыган саен, фикерләренең тирәнлегенә, эчкерсезлегенә игътибар иттем. Исламның тумыштан «үзенчәлекле» булуын белгәч, шәхсән танышасым килде.



Исламда балалар церебраль параличы. Балачактан ук аның башкалар кебек булмавын тирә-ягындагы кешеләр сиздермәскә тырыша. Шуңа күрә ул үзе дә башкаларга ярдәм итә алуына ышанып яши. «Әгәр дә миңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итсәләр, баш тартмаячакмын. Һәр кешенең дә бәхеткә хокукы бар бит».

Хәзер Ислам веб-сайтларны гамәлгә кую белән шөгыльләнә. Моңа бары тик махсус әдәбият укып, интернет аша гына өйрәнеп була икән. Инде клиентлары да шактый үзенең. Ислам сәламәтлегенең үзенчәлеген аңлап эшләргә тырыша. 2 сәгать буе компьютер артында утырып эшләгәннән соң, аңа ятып ял итү мәҗбүри. Өстәвенә, ул үзенең омтылышлары кемгәдер үрнәк, мотивация булсын дип, һәр көненә хисап язып, аны социаль челтәрләргә элә. Хәзер ул үз блогын башка төрле исем белән тәкъдим итә: «Бәхеткә кадәр 400 көн. Ислам Гаязетдинов блогы».

Бу кешеләргә «үзенчәлекле» дигән ярлык тагасы килми. Шулай да аларга сокланмый мөмкин түгел. «Минем төп проблема – тәндә түгел, ә үзем куйган киртәләрдә, тормыш биргән мөмкинлекләрне күрмәүдә, – ди Ислам, – Аллаһка рәхмәт әйтер мизгелләр бик күп минем язмышта».

Тормышка мәхәббәт – менә нәрсә хәрәкәтләндерә аларны. Һәр нәрсәгә уңай карау, авыр чакларда елмая белү, кешеләргә ярдәм итәргә тырышу, барысына рәхмәтле булулары өчен генә дә аларга сокланырга мөмкин. Шундый язмышка дучар булган татар халык шагыйре Фәнис Яруллин дөрес әйтә: «Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземлеләр генә бәхеткә лаек».

**Сораштыру**

Яңадан-яңа технологияләр барлыкка килгән чорда, электрон китаплар, интернет челтәре өстенлек алуга карамастан, урамда, метро, автобуста чын кәгазь китап укып баручылар юк түгел. Кызык, студентлар арасында кемнәр китапларның кайсы төренә өстенлек бирә икән?

# Китапның киләчәге бармы?

**Адилә ГЫЙЛАЕВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

● **Ландыш Гарифуллина, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**
Минемчә, китап уку беркайчан да актуальлеген җуймаячак. Мин китап укымаучыларга гомумән кырын карыйм. Фильмнар карап кына фикер йөртергә өйрәнеп, сөйләм телеңне яхшыртып булмый. Китап уку ул сәяхәт итү кебек, иң кызыгы, бу сәяхәт төрле гасырларга, елларга, дәүләтләргә була ала. Мин электрон китаплар уку ягында түгел, өйдә электрон китабым тузан җыеп ята.

● **Алисә Тимофеева, Педагогика һәм психология институты:**
Китап сөйләм телен үстерә, грамоталы язарга ярдәм итә. Кәгазь китапны кулга тотып, битләрен актара-актара уку – үзе бер рәхәт бит ул.

● **Руслан Хөснетдинов, Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты:**
Транспортта барган вакытта игътибар иткәнем бар, күпләр планшеттан, смартфоннардан китап укуны кулай күрә. Ләкин китапның үзен тотып уку – барыбер икенчерәк. Бәлки, ияләнгәнгә безгә шулай тоеладыр. Хәзерге балалар аны кечкенәдән электрон вариантта укып үссә, аларга кәгазь китап берничә елдан кыргый тоелырга да бик мөмкин.

● **Фаил Гыйниятов, КФУның Алабуга институты:**
Мин электрон китаптан укуны кулайрак күрәм, ләкин кәгазь варианты да тормыштан төшеп калыр дип санамыйм.

● **Динара Хәбибуллина, Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты:**
Китап – ул якын дус. Бүгенге көндә кирәк һәм кирәк булмаган мәгълүмат алу өчен электрон чаралар бик күп, ләкин кәгазьгә бастырылган китапны алар белән чагыштырып булмый.

**Фикер**

# «Darelfønyn» тәкъдим итә

Безнең редакция хезмәткәрләре китапның киләчәген ачык күрә. Заманның электронлашуына карамастан, алар әдәби әсәрләр укуны ташламыйлар. «Darelfønyn» редакциясе яраткан китаплар исемлеге белән сезне дә таныштыра.




✦ ***Ләйлә Сабирова (баш мөхәррир):***
Хәзерге вакытта үзем Зифа Кадырованың «Синсез килгән язлар» романын укыйм. Бүгенге көндә зур популярлык казанган язучының әлеге әсәре мәхәббәт хисен кадерләп сакларга, гаилә кыйммәтләре турында уйларга чакыра. Геройларның язмышлары, шатлык-сөенечләре, хаталары – укучыга гыйбрәт. Тормышта һәрбер әйбернең кадерен белергә, булганына сөенергә өйрәтә торган әсәр бу.




✦ ***Роза Асылгәрәева (корректор):***
Фәнис Яруллинның «Хәтер төпләрендә утлы күмер» китабын тәкъдим итәр идем. Биредә язучының авыр фаҗигагә юлыкканнан соң алып барган барлык көндәлекләре тупланган. Фәнис аганың дөньяда барган вакыйгаларга һәм шул заманның олы шәхесләренә карата булган уй-фикерләрен уку, алар белән танышу бик кызыклы һәм бик файдалы.

Минем өчен мөһим булган китапларның тагын берсе – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә»се. Әлеге китап та уйланулар рәвешендә язылган. «Ачы тәҗрибә»не бер тапкыр гына булса да кулына алган кеше, һичшиксез, яңа белемнәр һәм рухи байлык алачак дип уйлыйм.



✦ ***Руфинә Дунаева (корреспондент):***
Нинди дә булса бер генә әсәрне аерып алу бик читен. Шулай да Әмирхан Еникинең «Саз чәчәге»н укырга тәкъдим итәр идем. Миңа әлеге әдипнең иҗаты гомумән ошый. Теле, образларның бирелү рәвеше һәм, әлбәттә, укучыны уйландырырлык проблемалар сокландыра. Төп каһарманның күңел халәте табигатьтә дә кабатлана. Бу параллельне күзәтеп бару укучыдан әзерлек тә сорый әле. «Саз чәчәге»н укыган саен, шул чәчәккә әйләнергә язмасын дип телисең.




✦ ***Айгөл Абдрахманова (корреспондент):***
Джером Дэвид Сэлинджерның «Над пропастью во ржи» романы, һичшиксез, игътибарга лаек. Әсәрдә 17 яшьлек яшүсмернең җәмгыятькә мөнәсәбәте ачыктан-ачык чагыла. Егетнең гомум кабул ителгән кануннарга буйсынырга теләмәве, үз кагыйдәләре буенча яшәргә омтылуы романны үзенчәлекле һәм алыштыргысыз итә. Дөньяга карата күзаллауны үзгәртмәсә дә, балалар һәм яшүсмерләр психологиясе турында яңа белемнәр белән баета. Әлеге әсәр XX гасырның иң яхшы 100 романы исемлегенә кертелгән.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Дунаева, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.